**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Коморгузинского сельского поселения Атнинского муниципального района**
422758, с.Коморгузя, ул. Татарстана, зд.40Б
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы Комыргужа авыл жирлеге Советы**
422758, Комыргужа авылы, Татарстан урамы., 40Б нчы йорт
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
«15» ноябрь 2022 ел. № 5

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2022 елның 26 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авылында теркәлгән һәм Тукай урамы, Комсомоль урамы буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авыл җирлегендә теркәлгән һәм Татарстан урамы, Пионер урамы буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 26 ноябрь 12 сәгать 00 минутта билгеләргә

3. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитеты;
- халык җыенының беренче этабын үткәрү вакыты-2022 елның 26 ноябре-11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;
- халык җыенының икенче этабын үткәрү вакыты-2022 елның 26 ноябре-12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү урыны-Комыргуҗа авылы, Комсомоль урамы, 5 нче йорт янында;
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү урыны-Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 20 нче йорт янында;

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 22 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40Б йорт;

- сайлау хокукына ия булган Комыргуҗа торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Комыргуҗа торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Комыргуҗа авылы зиратын чистарту (агач кису, үлән чабу);

- Комыргуҗа авылында территорияне чистарту үлән чабу, транспорт хезмәтләре күрсәтү;

- Комыргуҗа авылы паркы территориясендә газон чабу (эш һәм хезмәт өчен түләү);

- урам яктырту (лампаларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) лампалар сатып алу;

- Комыргуҗа авылындагы парк территориясенә видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру (эш һәм хезмәт өчен түләү);

- Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу(эш һәм хезмәт өчен түләү);

6. 2022 елга гражданнар җыены буенча җыелган (экономияләнгән) үзара салым акчасын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

- Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Комыргуҗа авылы, Татарстан урамы, 40Б йорт, Комыргуҗа авылы, Пионер урамы, 22 йортлардагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8.Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән уз көченә керә.

9.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Низамиев